**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының**
**Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

№1 16 октябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча һәм авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге турында килешүне раслау хакында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 124, 125 һәм 421 статьялары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Тауасты Байлар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Башкарма комитетының «ТР Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган һәм Тауасты Байлар авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм мөлкәт белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге турында килешүне расларга.
2. Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга E-mailPbay.Mnz@tatar.ru
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З.С.Гәрәева